| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2025 ел Баулы шәһәре №112

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 139 номерлы карары белән расланган җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2025 елның 26 маендагы 67 номерлы, 2025 елның 7 июлендәге 91 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясындагы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 538-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 139 номерлы карары белән расланган җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2025 елның 26 маендагы 67 номерлы, 2025 елның 7 июлендәге 91 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5.2. пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, төзелгән бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәте әгъзалары Реестры.;

2.8.2.1.пуктында:

3) пунктчада «йә» сүзләреннән соң «җир кишәрлеген федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алуга хокукы булган бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәттә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган граждан йә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга (әгәр мондый җир кишәрлеге бакча булса), шулай ук искәрмә нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга хокуклы» сүзләрен өстәргә;»;

13) пунктчада «хуҗалык» сүзеннән соң «торак пунктлар чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

16) пунктчада «иң чик» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 сентябреннән  үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров